**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ФОМКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ФОМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Фома ав. **КАРАР**

«27» гыйнвар 2026 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегендә җирләү хезмәтләрен күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге хакының иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, шулай ук 2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен карарның 1нче кушымтасы һәм 2нче кушымтасы нигезендә 9678 сум 63 тиен күләмендә билгеләргә һәм 2026 елның 01 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге хакының иң чик күләмен раслау турында» 2025 елның 28 гыйнварындагы 1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Х. Абдрахманов

Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге башкарма комитетының 2026 елның 27 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1нче кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең иң чик күләме**.**

| № | Хезмәтләр исеме | Хезмәт бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 3 228,91 |
| 3. | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1 862,83 |
| 4. | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 4 586,89 |
| | Барлыгы | **9 678,63** |

Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге башкарма комитетының 2026 елның 27 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 2нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең иң чик күләме

| № | Хезмәтләр исеме | Хезмәт бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Мәетне кәфенләү (төрү) | 1 490, 27 |
| 3. | Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1 738,64 |
| 4. | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1 862,83 |
| 5. | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 4 586,89 |
| | Барлыгы | **9 678,63** |